БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# ВИЗИТ МУФТИЯ



В Абдулинском районе с официальным трехдневным визитом побывал муфтий Оренбургской области и председатель Духовного управления мусульман нашего региона Г.Хайруллин.

В первый день Габдельбарый хазрат и председатель местной татарской национально-культурной автономии Абдулинского района И. Зарипов встретились с главой района П. Мироновым (на снимке). В ходе встречи были обсуждены такие важные вопросы, как завершение начатого пять лет назад в г. Абдулино строительства новой мечети, а также сохранения в школах всех шести татарских сел количества часов для обучения родному языку и об увеличении их за счет факультативов. В последующие два дня Габдельбарый хазрат Хайруллин, Ильгизар Шаматович Зарипов и имам-хатыйб Абдулинской мечети Алмаз хазрат Кашапов ездили по району и встречались с единоверцами в татарских селах района, а также посетили мечеть г. Абдулино и села Степановка-2.

**З.ЗАРИПОВА.**
**г.Абдулино.**



# МИН БИТ ТАТАР БАЛАСЫ

Элек төрки халыклар Яңа елны 21 март көнне каршы алганнар һәм бу бәйрәмне Нәүрүз бәйрәме дип атаганнар. Нәүрүз сүзе фарсы теленнән тәрҗемә иткәндә, Яңа көн яки Яңа ел дигәнне аңлата. 21 март көнне туган балаларга да Нәүрүз дип исем кушканнар.

Авылыбызга нигез салучы Нәүрүз Тугаев та нәкь менә шушы көнне 1694 елның 21 мартында дөньяга килгән.

Нәүрүз бәйрәменә карата 20 март көнне кич белән авыл клубының сәхнәсендә Нәүрүз урта мәктәбе укучылары тарафыннан «Мин бит татар баласы» дигән КВН оештырылды. КВНда 9а сыйныфының «Шаяннар», 9б сыйныфының «Нәүрүз егетләре», 10 сыйныфның «Авыл балалары» командалары катнашты. Командалар жыр, бию, сатира һәм юмор бәйгеләрендә көч сынаштылар. Соңгы бәйгедә капитаннар татар теле һәм әдәбияте, татар мәдәнияте буенча үзләренең белемнәрен күрсәттеләр. Бәйгеләр арасында милли киемнәр кигән башлангыч сыйныф укучылары туган тел турында шигырьләр сөйләделәр, жырлар жырладылар. Жыр һәм бию конкурсында катнашкан укучылар дипломнар белән бүләкләнделәр. КВНда катнашкан һәрбер укучыга бүләкләр тапшырылды.

Бу бәйрәмнең иганәчесе фермер Хуснуллин Р.Х. һәрбер командага приз- татлы торт бүләк итте.Тамашачылар бу бәйрәмдә рәхәтләнеп ял иттеләр һәм канәгать булып өйләренә таралыштылар.

**Н.МУХАМЕТНУРОВА**
**Пономаревский район.**

**Фото С.КАМАЛИЕВА.**



# Горячая линия для мусульман

В Совете муфтиев России открыта горячая линия для мусульман, столкнувшихся с агрессией в связи с недавними террористическими актами в Москве. Совет муфтиев России просит всех тех, кто стал жертвой нападений, является свидетелем нарушения прав мусульман, либо обладает информацией об опасности для мусульман, проживающих в России, сообщать о подобных случаях по телефону горячей линии. Служба горячей линии будет оказывать правоохранительную, правовую и психологическую поддержку.

Телефон горячей линии: **8 (926) 911-24-11.**

# Кызыклы кичәләр уздырылды

Беренче апрельдә без көлке көнен билгеләп үттек. Матвеевка районының Иске Әшер мәдәният йортында бу көнгә карата кызыклы кичә узды. Авыл китапханәче Нәзимә Фасих кызы Галимова һәм мәдәният йортының оештыручысы Рита Сайранова бик матур итеп бәйрәмне оештырганнар иде. Авылыбызның яшьләре төрле конкурсларда, викториналарда катнашып бүләккә ия булдылар. Кичә барышында кызыклы итеп Верка Сердючка рәвешен, чегән киносының героинясе Кармелитаны бик килештереп күрсәттеләр. Бәйрәмнәрдә актив катнаштылар Роберт Шагиев, Артур Гыйльфанов, Азат Салимов, Алина Каримова, Рушат Шамкаев һәм башкалар.

Кичә дискотека белән тәмамланды.

**Артур НИЗАМОВ.**
**Матвеевка районы,**
**Иске Әшер авылы.**

# Чаңгы ярышы

Күптән түгел Матвеевка районы Иске Әшер авылында чаңгы ярышы узды. Ярыш Советлар Союзы Герое Әкрәм Белалович Шамкаевка арналды. Барлык чаңгышычларны һәм каpарга килүчеләрне Ә.Б.Шамкаевның кызы Тамара Әкрамовна Хәмидуллина, Иске Әшер авылының администрация житәкчесе Мансур Зәкәрия улы Тухбатов тәбрикләделәр. Шуңардан соң ярышлар башланды. Чаңгы ярышында барлыгы 16 мәктәп катнашты. Уңыш теләүчеләр кызыксынып, түземсезлек белән һәр чаңгычыга кул чабып тордылар. «Бик матур оештырылган чаңгы ярышы», — дип мактадылар оештыручыларны карарга килүчеләр. Беренче урынны Матвеевка мәктәбенең яшь чаңгычылары яулады. Аларга Советлар Союзы Герое Ә.Б. Шамкаевның күчмә кубогы тапшырылды. Икенче урынны Иске Әшер мәктәбе алды. Өченче урынга Иске Якуп чаңгышычылары чыкты. Ярышу оештыручыларга: Иске Әшер мәктәбе коллективына, администрация житәкчесе М.З.Тухбатовка, спортчылар М.З. Газизовка һәм спонсор Р.К. Гумировка, район тренерларына зур рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Артур НИЗАМОВ.**
**Матвеевка районы,**
**Иске Әшер авылы.**